| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУСЛЮМОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_21.02.2023_ Мөслим № _85_

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм дәүләт торак программалары буенча торак урын бирү нормасы турында» 2006 елның 8 сентябрендәге 157 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына һәм «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Торак базарын тикшерү турында» 2023 елның 8 февралендәге 29 номерлы хатына таянып, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданнар өчен: 17537,41 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен: һәр гаилә әгъзасына – 11160,16 сум;

1.1.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә: һәр гаилә әгъзасына – 9565,85 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 964 557,00 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 227 618,00 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 578 366,00 сум;

1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 104 488,00 сум;

1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 2 630 610,00 сум;

1.2.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 3 156 732,00 сум;

1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 3 682 854,00 сум;

1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 4 208 976,00 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасыры Д.З.Мухаметдиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Сәлихҗанов**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 21нче февраль
85 номерлы карарына
кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләмен исәпләү**

Торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган муниципаль берәмлекләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма кеременең максималь күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,25 х РС),** монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ – исәп күрсәткече;

ПС – бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (2022 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән ставкасы елга 8,62%, ягъни 8,62/100/12=0,005 – айга);

КП – кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2023 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән вакыты 292,1 ай);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;;

0,25 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы. «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Торак базарын тикшерү турында» 2023 елның 8 февралендәге 29 номерлы хаты нигезендә 2022 елда Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 29 229,00 сум тәшкил итә.

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләмен исәпләү

| НП - торак урының нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - Кредит буенча айлык процент ставкасы, (уртача еллык – 8,62%) (8,62/100/12) | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы. | ПД - керемнең иң чик күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 8 | 9 | 9 |
| 33 | 964557,00 | 1 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 0,25 | 17537,41 |
| 42 | 1227618,00 | 2 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 0,5 | 11160,16 |
| 54 | 1578366,00 | 3 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 0,75 | 9565,85 |
| 72 | 2104488,00 | 4 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1 | 9565,85 |
| 90 | 2630610,00 | 5 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1,25 | 9565,85 |
| 108 | 3156732,00 | 6 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1,5 | 9565,85 |
| 126 | 3682854,00 | 7 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1,75 | 9565,85 |
| 144 | 4208976,00 | 8 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 2 | 9565,85 |